Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

06 май 2020 ел № 587

Муниципаль ихтыяҗлар өчен
җир кишәрлеген алу турында

Россия Федерациясе Граждан кодексының 279, 281 статьялары, Россия Федерациясе Җир кодексының 11, 49, 56.3, 56.2, 56.6 статьялары, «Алсу» микрорайоны территориясен планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү буенча проект документациясен раслау турында» Әлмәт шәһәре башкарма комитетының 2020 елның 24 апрелендәге 55нче карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Әдип Маликов ур., 8 җ/к адресы буенча урнашкан, Әлмәт шәһәре, «Алсу» мкр., 16:45:00 00 00:697 кадастр номерлы, 663 кв.м. мәйданлы җир кишәрлеген 220 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасын төзү максатыннан Низамов Дамир Тәүфыйк улыннан алырга.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы (Пузырева И.Г.) әлеге карар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә:

- әлеге карарның 1 пунктында каралган хокук иясенә Россия Федерациясе Җир кодексының 56.6 статьясында каралган тәртиптә әлеге карарның күчермәсен җибәрергә;

- әлеге карарның күчермәсен Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Әлмәт бүлегенә (Әблеева Э.Б.);

- муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлеген алу турында килешү төзегәндә вәкаләтле орган булырга;

- алына торган җир кишәрлеген бәяләү буенча эшләр заказчысы булырга;

- тартып алу шартларына карата алынган күчемсез милек милекчесе белән сөйләшүләр алып барырга;

- сатып алына торган күчемсез мөлкәт милекчесенә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә күчемсез милекне тартып алу турында килешү проектын әзерләргә һәм җибәрергә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга .

4. Әлеге карар кабул ителгән көннән өч ел дәвамында гамәлдә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов